**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле  авыл җирлеге Үрнәк авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«22» ноябрь 2024 ел № 11

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 22 ноябрендә узган:

«Сез Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы территориясендә яшәүче һәм теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, СВОда катнашучылардан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:
- эчәр су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- Үрнәк торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, шул исәптән таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком, асфальт ватыклары (сатып алу ,ташу, салу), чокырларны ремонтлау (коелган асфальт);
- урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күпләп ял итә торган урыннары (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннары) товарларын (эшләрен, хезмәт күрсәтүләрен) сатып алу һәм аларга якын территорияне төзекләндерү);
- Үрнәк торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- Үрнәк торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы  сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 89 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 64 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 60 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 4 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле  авыл җирлеге Үрнәк авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.
2. Признать принятым решение по вопросу:

«Сез Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы территориясендә яшәүче һәм теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, СВОда катнашучылардан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл

итүгә юнәлтүгә ризамы?:
- эчәр су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- Үрнәк торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, шул исәптән таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком, асфальт ватыклары (сатып алу ,ташу, салу), чокырларны ремонтлау (коелган асфальт);
- урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күпләп ял итә торган урыннары (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннары) товарларын (эшләрен, хезмәт күрсәтүләрен) сатып алу һәм аларга якын территорияне төзекләндерү);
- Үрнәк торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- Үрнәк торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү төзекләндерү  мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.
3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле  авыл җирлеге Үрнәк авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.И. Кашапова

Киекле авыл җирлеге башлыгы: Л.И. Кашапова